ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "ЮГАРЫ КОЛЧУРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ"
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2019 елның 30 ноябре 22№

«Югары Колчура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында " 2018 елның 31 маендагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Югары Колчура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 31 маендагы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 1 пункты 2 пунктчасындагы 3 абзацында "(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)"сүзләрен өстәргә;

2 статьяның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата шәхси торак төзелеше, бакчачылык яки яшелчәчелек, шулай ук "Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре карата кадастр бәясенең 0,13% ы»;

4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестицион бизнес - проектларны гамәлгә ашыручы инвесторлар».

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Әлки муниципаль районы
Югары Колчура авыл җирлеге Советы Рәисе: Е.В. Краснова